| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

04.02.2021 № 49-р

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 сентябрендәге 522-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәреш кертү турында

РФ Юстиция министрлыгының 2017 елның 23 июнендәге 2754 номерлы боерыгы белән 2021 елның 17 гыйнварыннан норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә вәкаләтле бәйсез эксперт сыйфатында аккредитацияләнгән Р. М. Гибатдиновның бәяләмәсе нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эш төркеме төзү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 522-р номерлы күрсәтмәсенең 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтада 4.13 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Эшче төркем карарлары утырышта катнашкан эшче төркем әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигезлегендә эшче төркем җитәкчесенең, нигезле сәбәпләр аркасында (командировка, отпуск, больничныйда булганда) ул булмаган очракта эш төркеме җитәкчесе урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.

2 нче кушымтаның 4.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Эшче төркем рәисе карары буенча утырыш читтән торып үткәрелә. Утырышны читтән торып үткәрү турында карар кабул иткәндә, сорашып тавыш бирү юлы белән эшче төркем әгъзаларына мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә, шул ук вакытта читтән торып тавыш бирүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча, утырышны читтән торып уздыру турындагы карарда күрсәтелгән срокка кадәр дәлилләнгән позиция бирелә.».

Җитәкче Р.Р. Хәмзин